КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 апрель г.Казань № 258

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын раслау турында» 2022 ел, 23 июнь, 603 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын гамәлгә ашыру чаралары планына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын раслау турында» 2022 ел, 23 июнь, 603 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 9 ноябрь, 1447 нче, 2023 ел, 28 ноябрь, 1524 нче, 2024 ел, 26 апрель, 280 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын гамәлгә ашыру чаралары планына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 июнь, 603 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 22 апрель, 258 нче карары редакциясендә)

## 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын гамәлгә ашыру чаралары планы

| Чара | | Документ төре | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | 2 | 3 | 4 |
| 1. Балаларның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнщ алуын арттыру өчен шартлар тудыру | | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүдә катнашучы оешмалар челтәрен төзү | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.2. | Аларның фәнни-методик, медицина-биологик, медицина, допингка каршы һәм методик тәэмин итүне гамәлгә ашыру зарурлыгын исәпкә алып, спорт резервын әзерләүче оешмаларның матди-техник базасын булдыру | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 1.3. | Физик культура һәм спорт өлкәсендә тренерларга, тренер-укытучыларга һәм башка белгечләргә өзлексез белем бирү системасын булдыру, шул исәптән адаптив физик культура һәм спорт буенча, һәм тренерларның югары мәктәбен торгызу, аның нигезендә спорт төрләре буенча тренер кадрларының кадрлар резервын булдыру | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2026 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| 1.4. | Спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның коралланышына мониторинг һәм анализ ясау | Россия Федерациясе Спорт министр-лыгына доклад | 2025 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.5. | «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасында физик культура һәм спорт белән түләүсез нигездә шөгыльләнү өчен, барыннан да элек аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларга, күрсәткечләр эшләү һәм раслау | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 2. Россия Федерациясендә балалар-яшүсмерләр спорты өлкәсендә норматив хокукый җайга салу | | | | |
| 2.1. | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү өлешендә спорт резервын әзерләү өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3. Балалар-яшүсмерләр спорты белән идарә итүне, аны координацияләүне һәм методик тәэмин итүне камилләштерү | | | | |
| 3.1. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 декабрендәге 3894-р номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр Россия Федерациясендә балалар-яшүсмерләр спортын үстерү концепциясен гамәлгә ашыру мониторингын үткәрү һәм Татарстан Республикасында аның нәтиҗәлелеген бәяләү | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3.2. | 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына һәм Россия Федерациясе Спорт министр-лыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| 3.3. | «Барлык кешеләр өчен йөзү» ведомствоара программасын һәм аны гамәлгә ашыру чаралары | Россия Федерациясе | 2025 елның I кварталы, алга | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан |

| 1 | | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| | планын гамәлгә ашыру, шул исәптән балаларга тормышның төп күнекмәсе буларак йөзүгә өйрәтүне оештыру | Спорт министрлыгына доклад | таба - ел саен | Республикасы Спорт министрлыгы |
| 3.4. | Авыр тормыш хәлендә калган, шул исәптән эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә профилактик исәптә торучы балаларны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү буенча методик тәкъдимнәр эшләүдә катнашу | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдимнәр | 2025 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4. Балалар-яшүсмерләр спортының цифрлы трансформациясе | | | | |
| 4.1. | Спорт әзерлеге этапларында, шул исәптән спорт-сәламәтләндерү этабында, «Физик культура һәм спорт» бердәм цифрлы платформасы» дәүләт мәгълүмат системасына укучылар турында мәгълүмат тапшыру | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 5. Балалар-яшүсмерләр спортын үстерүне тәэмин итү буенча кадрлар потенциалын һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү | | | | |
| 5.1. | Мондый программалар буенча укучы затларда, физик культура һәм спорт өлкәсендә тренер-укытучыларда һәм белгечләрдә спортта допингка карата нульле түземлелек үрнәге булмау максатларында спорт әзерлегенең төрле этапларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларда допингка каршы тематика буенча белем бирү программаларын тарату һәм гамәлгә ашыру | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның декабре, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча) |
| 6. Физкультура чаралары һәм спорт чаралары системасын камилләштерү | | | | |
| 6.1. | Татарстан Республикасында барлык гомуми белем бирү оешмаларында мәктәп спорт клубларын берләштерүче спорт төре (төрләре) буенча мәктәп спорт лигасын төзүгә, шулай ук мондый клублар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм аларны финанс | Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары | ел саен | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча) |

| 1 | | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| | белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру | | | |
| 7. Балалар-яшүсмерләр спорты өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инфраструктурасын һәм матди-техник тәэмин ителешен үстерү | | | | |
| 7.1. | Авыл җирлегендә дә, эре шәһәрләрдә дә спорт объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның II кварталыннан башлап, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 8. Спорт, шул исәптән җайлаштырылган төре (төрләре) белән шөгыльләнү өчен спортка сәләтле балаларны сайлап алу һәм аларның спорт ориентациясе системасын камилләштерү | | | | |
| 8.1. | «Талант һәм уңыш» мәгариф фонды базасында һәм аның төбәк үзәкләрендә «Спорт» юнәлеше буенча белем бирү сменалары үткәрү | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 ел, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 8.2. | Татарстан Республикасында балаларны иртә физик үстерү үзәкләрен төзүгә һәм аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның II кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| 9. Балалар-яшүсмерләр спортын үстерүне тәэмин итә торган оешмаларда шөгыльләнүче балаларны патриотик тәрбияләү өчен шартлар тудыру | | | | |
| 9.1. | Социаль челтәрләрдә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә балалар-яшүсмерләр спортын, шул исәптән спортчыларны һәм блогерларны интеграцияләү, сәламәт яшәү рәвешен һәм физик активлыкны популярлаштыруга юнәлдерелгән контент булдыру юлы белән популярлаштыру | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад | 2025 елның IV кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча) |

| 1 | | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| 10. Балалар өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнә алуны арттыру максатларында балалар-яшүсмерләр спортын финанс белән тәэмин итү | | | | |
| 10.1. | Спорт әзерлегенә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын формалаштыру | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына мәгълүмат | 2026 елның III кварталы, алга таба - ел саен | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |